**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль район Советы**
**КАРАРЫ**

**“ 08” нче ноябрь 2018 нче ел** **№ 42-245**

**“Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2018 нче елның 12 нче апрелендәге “Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затларның, контроль-хисап органы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында” 35-197нчы номерлы карары белән расланган “Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затларны, контроль-хисап органы рәисен акчалата бүләкләү күләменә үзгәрешләр кертү турында”**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 нче елның 28 нче мартындагы “Татарстан Республикасында депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” 182 нче номерлы карары белән расланган 2018 нче елның 17 нче октябрендәге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү хакында" 940 нчы номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль район Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2018 нче елның 12 нче апрелендәге 35-197 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының “Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында” гы карарына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2018 елның 26 июнендәге 39-218 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 нче кызыл юлда “4,65” саннарын “6,72” саннарына алыштырырга.

2. Әлеге карар 2018 нче елның 1 нче октябреннән үз көченә керә һәм хокукый мөнәсәбәтләргә тарала.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru "Интернет" мәгълүмати - телекоммуникация челтәрендә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/. бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы** **Козлов В. М.**